СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2021 ел. № 31

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендәге 117 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 ел, № 236 Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 21.10.2019 ел, №117 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

1.1. 1.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru.) халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев